
***Бергәләп өйрәник***



***Бакчадагы һөнәрләр***

***Әти-әниләр өчен методик ярдәмлек***

***(6-7 яшь)***

# Мәкальләр

*Хезмәт төбе — хәзинә.

* Эше барның ашы бар.

* Тирләп эшләсәң, тәмләп ашарсың.

* Бакча ясамый, алма булмый.

* Эшләп ашасаң, һәр ризык балдай татлы була.

* Агачны яфрак бизәсә, кешене хезмәт бизи.

* Тырышкан табар, ташка кадак кагар.

* Биш әйткәнче, бер эшлә.

* Сүзең белән мактанма — эшең белән мактан.

## *Гөлсем апа*

Гөлсем апаны күрерсез,
Бакчабызга килсәгез,
- Менә безнең тәрбияче
Гөлсем апа, — диярбез.
- Кайнамаган салкын суны
Эчмәгез! — ди ул безгә,
Аның сүзен онытмыйбыз,
Кайткач та өебезгә.
— Үскәннәрем, — ди ул безгә,
Чиста булсын сөлгегез.
Бервакытта да авырмас
Сезнең матур күзегез.
Порошок белән юабыз,
Тешебезне агартып,
— Шикәр төсле булган ич, — ди
Гөлсем апа, яратып.
Әминә Бикчәнтәева

**Хәрәкәтле уен “ *Башмакчы”***

Балалар түгәрәк ясап басалар. Өлкәннәрдән берәү уенны оештыручы була. Ул, кулына бер башмак алып (уйнаучы балаларның аяк размерыннан башмак зуррак булырга тиеш), уртага баса. Җырлый:

Төрле һөнәр беләбез, Матур итеп тегәбез;

Асыл төсле җепләр белән

Башмак башын чигәбез.

Балалар аңа каршы, түгәрәк буйлап йөреп, җыр җырлыйлар:

Әй башмакчы, башмакчы,

Үзең — оста такмакчы.

Син җырлама такмагың,

Бир кияргә башмагың.

Балалар җырлап бетергәч, алып баручы башмакны 2 бала арасына куя һәм аларның иңнәренә кагыла. 2 бала икесе ике якка түгәрәк буйлап йөгереп китәләр. Кем беренче килеп җитә, шул башмакны кия. Ул «башмакчы» була. Уен яңадан башлана.